РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » 09 2022 г. №715

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының Авыл территорияләрен
комплекслы үстерү" муниципаль программасын раслау
турында» Ютазы муниципаль районы Башкарма
комитетының 14.08.2020 ел № 599 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«2013-2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 8 октябрендәге 235 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.04.2020 ел, № 330 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында һәм «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 14.05.2020 ел, № 387 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортында Программаның финанс белән тәэмин итү нигезләре һәм чыганакларына кагылышлы позициядә:

- п. 1 пунктчасын

а) Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 5 524 848, 00 санын 4 465 188, 00 сумга алыштырырга.

б) торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 3 128 102,40 санын 4 034 784,00 сумга алыштырырга.

г) пунктчасын өстәргә: Ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү -
1 620 000,00 сум.

- п. 2 пунктчасы

а) авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту 3 632 136,00 күрсәткечен 2 864 796,00 сумга алыштырырга.
б) Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 2 265 177,60 санын 2 477 856,00 сумга алыштырырга.
ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү - 380 000,00 сум.
- п. 3 пунктчасы
а) авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 76 734,00 күрсәткечен 58 464,00 сумга алыштырырга.
б) торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 67 416,00 санын 81 408,00 сумга алыштырырга.
г) пунктчасын өстәргә - ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү 20 000,00 сум.
- п. 4 пунктчасы
а) авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 3 211 866,00 күрсәткечен 2 447 136,00 сумга алыштырырга.
б) 1 280 904,00 - торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 1 546 752,00 сумга алыштырырга.
г) ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү 837 142,86 сум.
2. 7 п « Әбсәләм авылы, Совет урамында җәяүлеләр тротуары төзелеше" муниципаль программасы чаралары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Ярдәмче программаның (ведомство максатчан программасының) төп чараның исеме | Җаваплы башкаручы | Тормышка ашыруны башлау һәм тәмамлау срогы | Турыдан-туры көтелгән нәтиҗә (кыскача тасвирлама) | Программаның (кече программаның) максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) белән бәйләнеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 6 | Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә ял итү зонасын төзекләндерү | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары | 2022 | Ял зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыкларны булдыру һәм төзекләндерү | Уңайлы шартлар тәэмин итү |

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина